| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16. 11. 2018 ел Баулы шәһәре № 93

Баулы шәһәр Советының 2014 елның
11 ноябрендә кабул ителгән 113нче санлы
"Физик затлар милкенә салым турында"
карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 3 августында кабул ителгән «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешнең 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы шәһәр Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Баулы шәһәр Советының 2014 елның 11 ноябрендә кабул ителгән 113нче санлы «Физик затлар милкенә салым турында» карарына (Баулы шәһәр Советының 2015 елның 3 мартындагы 134нче санлы карары, 2015 елның 19 октябрендәге 17нче санлы карары, 2018 елның 20 апрелендәге 74нче санлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасының икенче абзацында "фатирлар" сүзеннән соң "фатир өлешләре" сүзләрен өстәргә;

2 пунктның 3 пунктчасының икенче абзацында «торак йортлар» сүзеннән соң «торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Баулы шәһәре Мэры, шәһәр Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ